| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

17.10.2025 Казан ш. 3691-р

Бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында” 07.08.2014 № 1620-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында” 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм «Граница» кадастр үзәге» ААҖ башкарган документациягә туры китереп, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ хатын исәпкә алып (09.10.2025 № 01А-04/2116) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында” 07.08.2014 № 1620-р карары (алга таба - № 1620-р карар) белән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, «Газпром трансгаз Казань» ААҖ милкендә булган, 9307 инвентарь номерлы, 16:24-6.936 реестр номерлы бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасын трасса үзгәртелү, 16:24:150201:4379, 16:24:150201:4378 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә ПРГ үзгәртеп ясалу сәбәпле территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, үзгәртергә. Бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасы озынлыгы гомуми мәйданы 54958 +/- 82 кв.м.лы территория рәвешендә 15239 м ны тәшкил итә.

2. Инвентарь номеры 9307 булган газ бүлгеч газүткәргечне эксплуатацияләү срогында назүткәргечнең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында” 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә № 1620-р Карарга (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 19.05.2017 № 1122-р, 23.06.2017 № 1397-р, 15.10.2018 № 3421-р, 07.06.2019 № 1801-р, 25.08.2023 № 2288-р Карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, 953,787 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 4,08962762 кв.км территорияне тәшкил иткән, инвентарь номеры әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән ЭПУ «Приволжскгаз» газ бүлү челтәренең (газүткәргечләрнең) «Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ тарафыннан 2013 елның 3 июненнән 2013 елның 13 декабренә кадәр әзерләнгән һәм «Газпром трансгаз Казань» тарафыннан 2013 елның 31 декабрендә килештерелгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасы, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп саклау зоналары чикләрен расларга.»;

1 нче кушымтада 9307 инвентарь номерлы бүлгеч газүткәргечләргә туры килгән юлны һәм “БАРЫСЫ” юлын әлеге門 карарга кушымтадагы редакциядә бәян итәргә (бастыру каралмаган).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Приложение
к распоряжению Министерства
земельных и имущественных
отношений Республики Татарстан
от _17.10.2025__ № _3691-р__
(опубликованию не подлежит)

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 112 | 9307 | РТ, Лаишевский р-н, н.п. Усады | 15 239 | d=110 Низкое давление; d=160 Низкое давление | 16:24-5:2001-1490.1 от 26.09.2001 16-16-13/040/2008-206 от 25.12.2008 |
| ИТОГО | | | 953787 | | |